# Мөхәммәт Мирза иҗатының тәрбияви әһәмияте

*С.И. Низамова*
*7нче сыйныф*

*Татарстан Республикасы*
*Минзәлә шәһәре “Гимназия”*
*гомуми белем бирү муниципаль*
*бюджет учреждениесе*



...Алынганчы бер-бер эшкә, уйла син...

...Ният кылсаң, инде читкә куйма син.


Мәйдан
Мөхәммәт
МИРЗА
ТЕРЕ СУ
Мөхәммәт
Мирза
МӨХӘММӘТ
МИРЗА


МӨХӘММӘТ
МИРЗА
АДӘМ
БАЛАСЫ
Мөхәммәт
Мирза
МӨХӘММӘТ
МИРЗА


Мәйдан
Чаллы
әдәби-нәфис,
иҗтимагый
журнал
/2011
гыйнвар
Мөхәммәт
МИРЗА

# <u>Аллаһ, иман</u>

- ...Фатихасын Раббыңнан сора гел.
- ...Тәүбә ит, бәндә, бер Ходаң каршыңда.
- Ходайдан бүтәнгә:
  – Колыңмын! – димәгез...
- Кайларда торсак та,
  Иманлы ит, Ходай!..
  ...Рух мәңгелек, җан бакый...

# Сабырлык, чыдамлык

- ...Күтелмәгән газапларга тарыма...
- ...Никадәрле кирәк - шулай чыда...
- ...-Түз, сабакташ, бул чыдам?!..
- Югалту һәм табу чиратлашып килер,

  Рәхәтенә, хәсрәтенә син түз генә.

  Аллана, баллана алма тик күз генә.

# ***<u>Иҗат</u>***

- Иҗатчыны үз теләгеннән артык берьялгызы калдырмагыз.
- Шигырьсез үткән көннәремне
  Җәһәннәмдәгедәй хис итәм...
- Даһи иҗат – шул ук догалык!..
- Таныйм, тоям, сөеп яшим дөньяны:
  Җаным иҗат рәхәтенә уралган.



# Нәфес

- Нәфесен тыялган – күңеле камил зат.
- Адәм  баласының тыелганга һәрчак нәфесе котырыр.
- Адәм баласының нәфсе – кәсебендә рухы кала гарип...
- Мәңгелеккә килгән кебек, нигә нәфсең котыртасың, и бәндә?!

# Әти – әни



- ...Әткәң-әнкәң фатихасы - ...

  ...Һәрчак шуларга сыен Син!
- Әткәң – туган илең, әнкәң – туган оялң...
- Ата-ана фатихасы – бәхеткә юл.
- Ата-ана рәхмәте – фатиха.



# *Кемнең-кем икәнен бел*

- …Явыз белән усалны һич бутама.
- …Якын йөрмә, шайтан орган - шулардыр…

…Үтмәс чирләрен йоктырып китәрләр.

- Саран һәрчак алдакчы.
- Әрсезнең үкенгәнен күрмәссең.



# Камиллек

- Адәм баласының заты камиллеге – күркәм инсафлыгы.
- Камиллеккә өлге – самим гадилеге.
- Гадилек – ныклык һәм ышаныч билгесе.

# Миһербанлык

- Миһербанлык – кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең иң күркәме.
- Миһербанлык – җанның иманга сыенуы.
- Миһербанлык базарда сатылмый,

  Әмма аны анда табып була.

# Өмет



- ...Өметем - яшәвем кыйбласы.
- ...Килеремне беркөн ялгыз итмә.
- Адәм баласының күңеле күгендә өметнең зуры.



# Күк

- Күкне “күп” димә.
- Күк мәңгелек китап. Укыйсың килсә, өнен йоклама.
- Күкләр сабак бирә... Төшенгән төшенер...
- Фәрештәләр хозуры бит ул күк, ничек анда булсын күңелсез.
- Һәркемнең тәнен – Җир,

Зур артистлар,
шагыйрьләр,
Җырчылар чыккан якта -
Чалманарат авылында
Туган Мөхәммәт Мирза.

Гүзәл Актаныш ягының
Табигать тәэсиреме?
Күп сынаулар аша үтеп,
Мирза булган зур кеше.

Такталачык авылында
Белем алган мәктәптә.
Тәртип бозып та йөрмәгән,
Күп укыган, әлбәттә.

Кызык, мәгънәле язмалар
Кулдан–кулга күп йөргән.
Гыйбарә һәм шигырьләре
Күп санда дөнья күргән.

Тагын бик күп еллар шулай
Иҗаты сөендерсен.
Якташыбыз белән һәрчак
Горурланырбыз, белсен!